ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 сентября 2015 г. № 5034

Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясының 2, 3, 5, 8 пунктлары, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (алга таба – административ регламент).

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага административ регламентны «Интернет» челтәрендә тиешле мәгълүмати системаларда һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру өчен «Мәгълүмати технологияләр үзәге» МАУга җибәрергә.

3. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Муниципаль милектәге җир участогын әлеге җир участогында урнашкан, милкендә дини яки хәйрия билгеләнешендәге бина, төзелмә яки корылма булган дини оешмаларга милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 12 августындагы 4786 номерлы;

2) «Социаль ипотека системасында торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 3 мартындагы 1242 номерлы.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2015 елның 8 сентябрендәге
5034 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясының 2, 3, 5, 8 пунктларында күрсәтелгән физик затлар, юридик затлар (алга таба – гариза бирүче) (1 нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба– Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – ҖММИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

ҖММИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 233 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:
дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.
Төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.
ҖММИ белешмә телефоны: (8552) 30-55-54.
Керү шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы (http:// www.nabchelny.ru).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча Башкарма комитет (ҖММИ) бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтында (https://www. nabchelny.ru.);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (ҖММИ):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша 30-59-12;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша: uzioip@yandex.ru.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында ҖММИ белгече тарафыннан һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Граждан кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.12.1994, № 32, ст. 3301 (алга таба –РФ ГК);

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, ст. 4147);

«Россия Федерациясендә Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба -137-ФЗ Федераль закон);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822) (алга таба -131-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Российская газета, 05.05.2006, № 95; Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.05.2006, № 19, ст. 2060; Парламентская газета, 11.05.2006, № 70-71) (алга таба - 59-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179) (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә алуга хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы Приказы (Рәсми хокукый мәгълүмат порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015) (алга таба – 1 номерлы Приказ);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы (РеспубликаТатарстан, № 155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы);

Башкарма комитетның 2008 елның 17 ноябрендәге 1259 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезләмә (алга таба – ҖММИ турында нигезләмә);

Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

Башкарма комитетның 2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары (Башкарма комитетның 10.06.2013 №3487, 07.08.2013 №4712, 22.10.2013 №6360, 25.02.2014 №1139, 07.05.2014 №2654, 13.05.2014 №2708, 25.07.2014 №4366, 04.03.2015 №1359 карарлары) (алга таба– Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге).

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта).

## 2. 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү | РФ ҖК 39.5 ст. 2,3,5,8 пунктлары РФ ҖК 39.17 ст.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органының исеме | Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе исеменнән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 6 ст.;<br>шәһәр Уставының 41 ст.;<br>ҖММИ турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү турында карар, җир участогын кабул итү-тапшыру акты<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ГК<br>РФ ГК 39.1 ст. 1 п.<br>РФ ҖК 39.5 ст. 2,3,5,8 пунктлары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза теркәлгән вакыттан башлап 30 көннән артмый | РФ ҖК 39.17 ст.5 п. |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы | 1) гариза;<br>2) шәхесне таныклаучы документлар;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта;<br>4) территориянең кадастр планында җир участогының расланган урнашу схемасы (әгәр җир участогын барлыкка китерергә кирәк булса һәм аның чикләрендә җир участогы барлыкка килү күздә тотылган территориянең межалау проекты расланмаган булса) | РФ Җир кодексы<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон<br>Приказ №1 |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | Муниципаль хезмәттән файдаланучының категориясенә бәйле гариза бирүче тарафыннан бирелә торган өстәмә документлар исемлеге 3 нче кушымтада бирелгән | |
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Муниципаль хезмәттән файдаланучының категориясенә бәйле ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган өстәмә документлар исемлеге 3 нче кушымтада бирелгән | Приказ №1 |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>2) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе;<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе;<br>4) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе. | Эш регламентының 3 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) тапшырылган документлар регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) документларда аларның эчтәлеген бертөрле аңларга мөмкинлек бирми торган килешенмәгән төзәтүләр, җитди бозулар булу;<br>4) документларның тиешле органга бирелмәве. | РФ ҖК 39.17 ст.3 п. |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир участогы бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>2) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мираска ия булу яки аренда хокукында бирелгән, җир участогы бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать очраклардан тыш;<br>3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару яки индивидуаль торак төзелеше максатында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән оешмага бирелгән, гариза белән әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзасы яисә, җир участогы гомуми файдаланудагы мөлкәткә караса, әлеге коммерцияле | РФ Җир кодексның 39.16 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | булмаган оешма мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш;<br>4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яисә юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут, гавами сервитут нигезендә урнашкан яки җир участогында Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 пункты белән каралган объектлар урнашкан һәм ул җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалануга комачауламый яисә яисә җир участогы бирү турында гариза белән әлеге бина, корылма, алардагы бинаның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) җир участогында сервитут, гавами сервитут нигезендә урнашкан яки җир участогы бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алардагы бүлмәләр, әлеге тәмамланмаган төзелеш объектының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>6) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны бирү җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча рөхсәт ителми;<br><br>7) җир участогы бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җир булып тора, әгәр гариза бирүче җир участогын милеккә бирү турындагы гариза белән, җир участогын резервлау максатларында җир участогы бирү турындагы карарның гамәлдә булу срогыннан артык вакытка түләүсез файдалануга бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җир участогын резервлау максатларында бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән төзелә торган территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, җир участогы бирү турында гариза белән шул җир участогында урнашкан бина, корылмалар, алардагы бүлмәләрнең, тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе яки җир участогының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогы чикләрендә урнашкан яки җир участогы башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән ясалган, мондый җир участогы федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир участогын бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 10) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документ нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның әлеге объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотучы территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир участогын бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы, аны үткәрү турында белдерү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукцион предметы булып тора;<br>12) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогына карата, аны сату буенча аукцион үткәрү яки аны арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион үткәрү турында РФ Җир кодесының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 белән каралган гариза кергән, әгәр мондый җир участогы РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 4 пунктчасы нигезендә барлыкка килгән һәм вәкаләтле орган тарафыннан РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пункты белән каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса;<br>13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата РФ Җир кодексының 39.18 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир участогы бирү турында белдерү басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14) җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану мондый җир участогыннан җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән файдалану максатларына туры килми, линия объектын территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге объектлар төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>16) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогына карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;<br>17) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы җирләрнең билгеле бер категориясенә кертелмәгән;<br>18) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм аның гамәлдә булу срогы чыкмаган һәм җир участогы бирү турындагы | |

| | | |
|---|---|---|
| | гариза белән бу карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир участогын бирү максаты мондый җир участогын тартып алу максатларына туры килми, мондый җир участогында урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш;<br>20) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының чикләренә «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төгәллек кертелергә тиеш;<br>21) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы алар нигезендә мондый җир участогы төзелгән җир участогының урнашу схемасы, территорияне межалау проекты яисә урман участокларының проект документларында күрсәтелгән мәйданыннан ун проценттан артып китә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезе, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр | Бина гариза язу өчен өстәл һәм урындыклар, гариза тутыру үрнәкләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итүләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерак эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацон технологияләрне файдаланып | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://www.nabchelny.ru), Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru) муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерак эш урыннарында күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ хезмәткәре гамәлгә ашыра. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон рәвештә бирү каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) белдерү кәгазен кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша ҖММИгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

ҖММИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яисә вәкаләтле зат аша Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада тутыра һәм Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет – кабул итү бүлмәсе аша җибәрә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткәндә);

3) регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерүне;

4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның күчермәләре тиешенчә рәсмиләштерелүне, документларда бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызган сүзләр булмауны) тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

-гаризаны һәм теркәлгән документларны кабул итүне һәм махсус журналда теркәүне;

-гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтнең датасы һәм башкару вакыты турында тамга белән тапшырылган документлар исемлегенең күчермәсен бирүне;

теркәлгән гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Регламентның 2.8 пункты нигезендә документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гариза бирүчегә гаризаны документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза яисә кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза документлар.

3.3.2. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза кергән көнне гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИ башлыгына җибәрә.

3.3.2 һәм 3.3.3 пунктлары белән билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. ҖММИ башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгына (алга таба-ҖММИнең бүлек башлыгы) җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИнең бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. ҖММИ Бүлек башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИ җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгеченә җибәрә (алга таба – ҖММИнең бүлек белгече).

3.3.4 һәм 3.3.5 пунктларында билгеләнә торган процедура гариза карап тикшерүгә кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. ҖММИнең бүлек белгече гамәлгә ашыра:

1) норматив-хокукый базаны исәпкә алып, гариза һәм документларны карап тикшерә;

2) ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә документларны (мәгълүматларны) тапшыру турында запрослар формалаштыра һәм җибәрә. Документлар (мәгълүматлар) исемлеге хезмәттән файдаланучыларның категориясеннән чыгып билгеләнә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон рәвештә җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документлар (мәгълүматлар) бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ҖММИ белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүмат) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. ҖММИнең бүлек белгече кергән документлар (мәгълүматлар) нигезендә:

-җир участогын милеккә бирү турында Башкарма комитет карары проектын (алга таба – карар проекты) яки әлеге Регламентның 2.9 пункты белән каралган нигезләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли;

-карар проектын яки баш тарту турында хатны килештерү өчен ҖММИ бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар запросларга җавап кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен ҖММИ нең бүлек башлыгына җибәрелгән карар проекты яки баш тарту турында хат.

3.5.2. ҖММИнең бүлек башлыгы:

- карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә;

- баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм аны имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән карар проекты яки имзалау өчен баш тарту турында хат.

3.5.3. ҖММИ башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә (алга таба – АШТһТҮИ) килештерү өчен җибәрә яки баш тарту турында хатны имзалый.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм килештерү өчен АШТһТҮИгә җибәрелгән карар проекты яки теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән баш тарту турында хат.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.4. АШТһТҮИ карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә яисә карар проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм аларны төзәтү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

АШТһТҮИгә карар проектына карата кимчелекләр җибәрелгән очракта ҖММИ бүлеге белгече әлеге кимчелекләрне төзәтә һәм төзәтелгән карар проектын АШТҺТҮИгә килештерүгә җибәрә.

АШТһТҮИ карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Хокук идарәсенә килештерүгә җибәрелгән карар проекты.

Процедураны гамәлгә ашыру срогы – 2 көн.

3.5.5. Хокук идарәсе карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Хокук идарәсе карар проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм аны кимчелекләрне төзәтү өчен ҖММИнең бүлек белгеченә җибәрә.

ҖММИнең бүлек белгече кимчелекләрне төзәтә һәм төзәтелгән карар проектын Хокук идарәсенә килештерүгә җибәрә.

Хокук идарәсе төзәтелгән карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

Срок- 3 көн.

3.5.6. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе:

1) карар проектын ахыргы вариантта тикшерә;

2) Башкарма комитет вазыйфаи затларының кирәкле визалары, карарга тарату кәгазе булуын (булмавын) тикшерә;

3) карар проектын Башкарма комитет бланкында бастырып чыгара;

4) карар проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең

беренче урынбасарына җибәрелгән карар проекты.

3.5.6 пункты белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.7. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары карар проектын имзалый һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгеченә (алга таба - эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече) җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

Срок – ике көн.

3.5.8. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

карар проектын яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны терки;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә. Башкарма комитетның җир участогын бирү турындагы теркәлгән карарын яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны бирү датасын хәбәр итә;

гариза бирүчегә имзасын куйдырып яки почта аша Башкарма комитет карарын яки баш тарту турында хат җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (ышаныч язуы буенча аның вәкиленә) бирелгән Башкарма комитет карары яки баш тарту турында хат.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карар яки баш тарту турында хат имзаланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.9. ҖММИнең бүлек белгече Башкарма комитет кабул иткән карар нигезендә җир участогын кабул итү-тапшыру актын әзерли һәм ҖММИ башлыгына килештерүгә җибәрә.

Срок – 3 көн.

Процедура нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына килештерүгә җибәрелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.5.10. ҖММИ башлыгы җир участогын кабул итү-тапшыру актын карап тикшерә, килештерә һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына имзалау өчен җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.5.11. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары җир участогын кабул итү-тапшыру актын имзлый һәм ҖММИ белгеченә җибәрә.

Срок – ике көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан имзаланган һәм ҖММИ белгеченә җибәрелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.5.12. ҖММИ бүлеге белгече гариза бирүчегә (яки аның вәкиленә ышаныч кәгазе буенча) хәбәр итә, җир участогын кабул итү-тапшыру актын тапшыра.

Срок -3 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) имзалау өчен бирелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.5.13. Гариза бирүче җир участогын кабул итү-тапшыру актын имзалый һәм теркәү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге процедураның срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.5.14. ҖММИ бүлеге белгече:

1) теркәү журналында җир участогын кабул итү-тапшыру актын терки;

2) гариза бирүчегә яки аның вәкиленә 1 нөсхәдә җир участогын кабул итү-тапшыру акты бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 30 минут дәвамында, чират тәртибендә, гариза бирүченең килгән көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.6. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар регламентның 3.3-3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документларны кабул итү өчен җаваплы белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны һәм теркәлгән документларны кабул итүне, теркәүне гамәлгә ашыра һәм аларны ҖММИгә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен ҖММИ белгеченә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, ҖММИ белгече муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып һәм имза куйдырып, техник хата булган документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен ҖММИгә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турындагы хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруны билгеләнгән тәртиптә үткәрелгән тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүен контроль тикшерүләрне билгеләнгән тәртиптә үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында рәсми язулар бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтүне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы Башкарма комитет вазыйфаи затларының исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы

нигезнамәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренең үз вакытында каралмавы өчен җаваплы.

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларның үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә ҖММИ эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1. статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮ, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, КФҮнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең

билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш.

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза

бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.9. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.5 статьясы. Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогы гражданга яки юридик затка бушлай бирү очраклары

Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир участогы гражданга яки юридик затка вәкаләтле орган карары нигезендә бушлай түбәндәге очракларда бирелә:

2 пунктча: дәүләт һәм муниципаль милектәге җир участогын милкендә дини яки хәйрия билгеләнешендәге бина, төзелмә яки корылма булган, әлеге җир участогында урнашкан дини оешма биргәндә;

3 пунктча: бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караучы җир участогын әлеге коммерцияле булмаган оешмага биргәндә яки Федераль законда каралган очракларда әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларының гомуми милкенә биргәндә;

5 пунктча: Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 7 пунктчасы нигезендә, аңа җир участогы бирелгән көннән башлап биш ел узгач, җир участогын гражданга биргәндә, әгәр әлеге граждан әлеге җир участогыннан күрсәтелгән чорда билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдаланган һәм муниципаль берәмлектә һәм Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлек буенча эшләгән очракта;

8 пунктча: дини оешмага даими (сроксыз) файдалану хокукында бирелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән җир участогын Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда әлеге оешмага биргәндә.

2 нче кушымта

Кемгә

______________________________________________

(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

кемнән_____________________________________________
_

(физик затлар өчен - фамилия, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документ реквизитлары, ИНН)

________________________________________________

(юридик затлар өчен - исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛ, ОГРНда дәүләт теркәве турында мәгълүматлар)

________________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, телефон номеры)

Җир участогын милеккә бушлай бирү турында
гариза

Сездән _________________________________________ нигезендә
(РФ Җир Кодексының 39.5 статьясында каралган нигезләрнең берсе күрсәтелә).

_____________________________________________________________________

(җир участогыннан файдалану максаты)

максатларда
мәйданы ___________ кв.м., кадастр номеры ________, түбәндәге адрес буенча урнашкан: ___________ муниципаль районы (шәһәр округы), торак пункт______________________________ _______________________ урамы __________йорт
бирүне сорыйм.

Өстәмә мәгълүматлар (түбәндәге шартлар булганда күрсәтелә):

_____________________________________________________________________________

территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турындагы карар реквизитлары, әгәр җир участогы әлеге документта һәм (яки) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелсә;
җир участогын бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары
____________________________________________________________

(гариза бирүче элек сорала торган җир участогын бирүне алдан килештерү турында гариза белән вәкаләтле органга аны ясау яки аның чикләрен ачыклау максатында мөрәҗәгать иткән һәм вәкаләтле орган тарафыннан сорала торган җир участогы бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән очракта тутырыла)

Гаризага түбәндәге документлар (сканкүчермәләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) территорияләрнең кадастр планында җир участогын урнаштыруның расланган схемасы (әгәр җир участогы төзергә кирәк булса һәм чикләрендә җир участогы төзү каралган территорияне межалау проекты расланмаган булса).

Юридик затлар:

1) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

2) территорияләрнең кадастр планында җир участогын урнаштыруның расланган схемасы (әгәр җир участогы төзергә кирәк булса һәм чикләрендә җир участогы төзү каралган территорияне межалау проекты расланмаган булса).

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_______________ ___________________

(_______________________________________)

(дата) (имза) (Ф. И. А.и.)

3 нче кушымта

Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә
алу хокукын раслый торган документлар
исемлегеннән өземтә

| N т/б | Сатулар үткәрмичә җир участогын бирү нигезе | Җир участогын бушлай яки түләү нигезендә бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Гариза бирүче | Җир участогы | Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир участогына хокук алу турында гаризага теркәлә торган документлар |
|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 2 пунктчасы | Милеккә бушлай | Милкендә дини яки хәйрия билгеләнешендәге бина яки корылма булган дини оешма | Милкендә дини яки хәйрия билгеләнешендәге бина яки корылма булган дини оешма урнашкан җир участогы | * Мондый бинага, корылмага хокук ЕГРПта теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ |
| | | | | | * ЕГРПта теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документ |
| | | | | | * Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) сорала торган җир участогында урнашкан барлык |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | биналар, корылмалар исемлеге, кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм гариза бирүчегә тиешле хокукта карый торган биналарның, корылмаларның адреслы ориентирлары күрсәтелгән хәбәре |
| | | | | | * Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br>* сорала торган җир участогында урнашкан барлык биналар, корылмаларның кадастр паспорты<br>* Күчемсез милек объекты (алына торган җир участогына һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларына хокуклар турында ЕГРП тан өземтә<br>*ЕГРЮЛдан гариза бирүче юридик зат турында өземтә |
| 13. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 3 пунктчасы | Гомуми милеккә бушлай | бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнар тарафыннан | бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнар тарафыннан | Гариза бирүченең, коммерцияле булмаган оешма әгъзасы булуын раслаучы документ |
| | | | | | * расланган территорияне межалау проекты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | төзелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзалары | төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караучы җир участогы | * коммерцияле булмаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (расланган территорияне межалау проекты булмаган очракта) |
| | | | | | * * Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә (аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килү очрагыннан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән ЕГРПта сорала торган мәгълүматларның булмавы турында белдерү кәгазе<br><br>* граждан аның әгъзасы булып торган коммерцияле булмаган оешма турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| | | | | | * алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә |
| 14. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 5 пунктчасы | милеккә бушлай | Төп эш урыны буенча Россия Федерациясе субъекты | муниципаль берәмлектә индивидуаль торак төзелеше | Эшкә алу турында приказ, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яки хезмәт шартнамәсе (контракт) |
| | | | | | * Сорала торган җир участогының |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | законнары буенча билгеләнгән белгечлек буенча муниципаль берәмлектә эшләүче граждан | яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен Россия Федерациясе субъекты законнары буенча билгеләнгән җир участогы | кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе |
| | | | | | * Алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә (аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килү очрагыннан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән ЕГРПта сорала торган мәгълүматларның булмавы турында белдерү кәгазе |
| 15. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 8 пунктчасы | милеккә бушлай | Даими (сроксыз) файдалану хокукында авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән җир участогы булган дини | Җир участогы бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законнары буенча билгеләнә | җир участогы алуга хокукны раслый торган Россия Федерациясе субъекты законнары белән билгеләнгән документлар |

<1> Документлар төп нөсхәдә (әгәр документлар һәркем файдалана алырлык булса күчермәдә) яисә җир участогына хокук алу турында гариза кабул итүче башкарма хакимият органының яки җирле үзидарә органының вазыйфаи заты таныклый торган күчермәләрендә тапшырыла (җибәрелә).

№2> Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, №44, 4147; 2014, №26, ст. 3377.

"*" символы белән билгеләнгән документлар муниципаль милектәге җир участоклары белән идарә итүгә вәкаләтле орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша соратып алына.

4 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлләренең эзлеклелек блок-схемасы




Нигез
Юк
ҖҺММИ бүлеге белгече алынган документлар нигезендә:
карар проектын яки баш тарту турында хат әзерли;
карар проектын килештерүгә яки имзалау өчен баш тарту турында хат ҖҺММИ башлыгына җибәрә
ҖҺММИ бүлеге белгече баш тарту турында хат
баш тарту турында
Карар проекты
ҖҺММИ башлыгы:
карар проектын килештерә яки баш тарту турында хат имзалый;
карар проектын килештерүгә АШТҺТҮИгә яки баш тарту турында имзаланган хатны теркәүгә җибәрә
Килештерелгән карар проекты яки баш тарту турында имзаланган хат
АШТҺТҮИ карар проектын килештерә һәм килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә яисә карар проектына кимчелекләрне әзерли һәм төзәтү өчен ҖҺММИ бүлеге белгеченә җибәрә
Килештерелгән карар проекты
ҖҺММИ бүлеге белгеченә кимчелекләрне төзәтә һәм карар проектын килештерү өчен АШТҺТҮИ гә җибәрә
Башкарма комитетның Хокук идарәсе карар проектын килештерә һәм Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә яисә карар проектына кимчелекләрне әзерли һәм төзәтү өчен ҖҺММИ бүлеге белгеченә җибәрә
җибәрә
Килештерелгән карар проекты
ҖҺММИ бүлеге белгеченә кимчелекләрне төзәтә, карар проектын килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә
җибәрә
Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе Регламентның 3.5.6 пунктында билгеләнгән процедураларны башкара
Имзалау өчен карар проекты
Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары карар проектын имзалый, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгеченә җибәрә
Имзаланган карар проекты
Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе Регламентның 3.5.6 пунктында билгеләнгән процедураларны башкара
Гариза бирүчегә бирелгән Башкарма комитет карары яки баш тарту турында хат

ЖҺММИ бүлеге белгеченә кабул ителгән карар нигезендә җир участогын кабул итү-тапшыру актын әзерли, килештерү өчен ЖҺММИ бүлеге башлыгына җибәрә

килештерү өчен ЖҺММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән кабул итү-тапшыру акты

ЖҺММИ бүлеге башлыгына кабул итү-тапшыру акты карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә

Килештерелгән, имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән кабул итү-тапшыру акты

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары кабул итү-тапшыру актын имзалый, ЖҺММИ бүлеге белгеченә җибәрә

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары имзалаган, ЖҺММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән кабул итү-тапшыру акты

ЖҺММИ бүлеге белгече җир участогын кабул итү-тапшыру актын (расписка алып) гариза бирүчегә яки ышаныч кәгазе буенча аның вәкиленә имзалау өчен

гариза бирүчегә җибәрелгән җир участогын кабул итү-тапшыру актын

гариза бирүче җир участогын кабул итү-тапшыру актын имзалый, теркәү өчен ЖҺММИ бүлеге белгеченә кире кайтара

ЖҺММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән җир участогын кабул итү-тапшыру актын

ЖҺММИ бүлеге белгече имзаланган җир участогын кабул итү-тапшыру актын журналда терки, бер нөсхәдә гариза бирүчегә яки ышаныч кәгазе буенча аның вәкиленә бирә.

гариза бирүчегә бирелгән җир участогынкабул итү-тапшыру акты

6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлегенең
Башкарма комитет
Җитәкчесенә
_______________________________
Кемнән: _______________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
______________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган: ____________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне: ______________________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_______________ _________________ ( _________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның
үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Nail.Magdeev@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары | 30-55-42 | Rinat.Abdullin@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | Lyuciya.Kudryashova@tatar.ru |

Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Nail.Magdeev@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары | 30-55-42 | Rinat.Abdullin@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | Lyuciya.Kudryashova@tatar.ru |